# Татар теле.

*Тема: Тиңдәш кисәкләр.*
*4в сыйныфы*
*татар төркеме*
*Укытучы: Р. М.Зәйнуллина*

Уникенче май.
Пәнҗешәмбе.
Сыйныф эше.



Матур язу.

*Ура, суга, җилгәрә,*
*Үзе тияп җибәрә.*



*Яктыра кала, урамнар, кырлар, якын урманнар.*

*Таулар, таллар, бакчалар нурга гарык булганнар.*

*Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.*

*Җәй көне. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм; Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.*

***Габдулла Тукайның тагын нинди шигырьләрен беләсез?***



***Сайланма диктант.***

*Бирем. Тиңдәш кисәкләрне сайлап яз.*

**Ат, сыер, эт, мәче, сарык, кәҗә - йорт хайваннары.**








**Азат, Рөстәм һәм Гөлнур лагерьда булдылар.**



Болында кызыл, сары, зәңгәр чәчәкләр үсә.



# Нинди матур, иркен, саф һавалы,
# Нинди күркәм безнең языбыз!







Тәлинкә, кашыклар,
Чәнечке, пычаклар
Тарата дежурный –
Аш урыны әзерли.






***Күзләрне ял иттереп алыйк***



# Бирелгән схемалар буенча җөмләләр уйлап әйтегез.



**Дәреслек белән эш.**

**142 нче бит.**

***349 нчы күнегү.***

*Сәнгатьле итеп укыгыз һәм күчереп язгыз. Тиңдәш кисәкләр янындагы тыныш билгеләрен аңлатыгыз.*

*Тиңдәш кисәкләр кайсы килештә килгән?*

*Шигырьнең эчтәлегеннән 2 яки 3 зат исеменнән сөйләгез.*

**Карточка белән эш.**

*Тиңдәш кисәкләрне табыгыз, алар кайсы сүзгә караганнар? Алар янында нинди тыныш билгеләре куелган? Дөрес интонация белән укып күрсәтегез.*

**Тест.**

1. Тиңдәш кисәкләр:

    а) бер үк сорауга җавап булган һәм саналып киткән җөмлә кисәкләре

    ә)кабатланып килгән сүзләр

    б) хәбәрне белдергән сүзләр.

2.Бу җөмләдәге тиңдәш кисәкләр нинди сүз төркеме белән бирелгән?

Синең сүзең, Тукай, туры булган

Кырлай каеннары шикелле.

Урманнары, кыры, инешләре

Бигрәк якын, бигрәк сөйкемле.(С.Сөләйманова)

а) исем

ә)фигыль

б) алмашлык

3. Нинди җөмлә кисәге?

Сибеп киткән саф, тук орлыкларың
Уңдырышлы туфрак таптылар,
Син үстергән матур , затлы гөлләр
Бөреләнеп чәчәк аттылар!(Г. Лотфи)

а) хәл

ә) аергыч

б) хәбәр

4. Тиңдәш кисәкләр янында

а) өтер генә куела

ә) барлык тыныш билгеләре дә куела

б) сызык куела

Тестны тикшерәбез.

1. а
2. а
3. б
4. а



Өй эше.

351 нче күнегү. Рәсемне карагыз. Тиңдәш кисәкләрне кертеп, “Безнең сыйныф” исемле кечкенә хикәя төзеп языгыз.



# Сез иң яхшы укучылар!

